| ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН II СОЗЫВА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ II ЧАКЫРЫЛЫШ ШӘҺӘР СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 июль, 2015 ел № 41/7

Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы 25/8 санлы Карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында Нигезнамәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 мадәсе, 2006 елның 13 мартындагы «Реклама турында» 38-ФЗ санлы Федераль законның 10, 19 маддәләре, шәһәр Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы 25/8 санлы Карары (Шәһәр Советының 2014 елның 23 декабрендәге 36/7 санлы Карары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында Нигезнамәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 5 пунктта:

- 12 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) предметы реклама корылмасын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү төзү хокукы булган сатуларда башлангыч бәяне билгели;»;

- 22 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«корылма проектын килештергәндә, 1992 елның 7 февралендәге «Кулланучылар хокукын яклау турында» 23300- I санлы РФ Законы яки гамәлдәге тәҗрибә буенча әлеге корылманың реклама яисә тышкы

мәгълүмат чарасы булуын билгели. Бу очракта Россия Федерациясе Югары суд Пленумы, Россия Федерациясе Югары Арбитраж суды Пленумы, Россия Федерациясе Югары суд Президиумы, Россия Федерациясе Югары Арбитраж суды Президиумы Карарларына, Россиянең монополиягә каршы федераль хезмәт тәкъдимнәренә һәм Россия Федерациясе территориясендә урнашкан суд тәҗрибәсенә таяна;»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 9 абзацны өстәргә:

«реклама корылмасының хуҗасы реклама корылмасының тиешле техник торышы өчен җаваплы, әгәр башкасы реклама корылмасын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү белән каралмаса.»;

3) 22 пунктта:

- 1 пунктчаның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбә җайланмасы имиджлы реклама конструкциясе булып тора һәм Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә килештерелгән реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын объектта урнаштыру концепциясе нигезендә оешманың торган урынына бәйләнешсез урнаштырыла.»;

- 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) фон корылмасы – реклама корылмаларын һәм тышкы мәгълүмат чараларын объектта урнаштыру концепциясе нигезендә каркаста ящерен ныгыту ысулы һәм бизәлеп эшләнгән читләр (багет) белән мәгълүмат мәйданы күренешендә биналарның, төзелмәләрнең стеналарында урнаштырылучы шәхси реклама корылмасы.

Бина фасадында урнашкан фон корылмасының киңлеге фасад киңлегенең 2/3 нән артырга тиеш түгел, ә реклама корылмасының өске кырые чиктәш фасадның өске тәрәзә уемыннан югары булырга тиеш түгел.

Суперграфика белән бина фасадында фон корылмасын урнаштыру рөхсәт ителми.

Суперграфика – фасадларны архитектур-сәнгати бизәү алымнарының визуаль үзләштерүне көчәйтә торган бер төре (рәсем, бизәк, барельеф, мозаика).

Коймада урнаштырылган фон корылмасы вакытлы реклама корылмасы булып тора.

Коймада урнаштырылган фон корылмасы койма секциясенең өске ягына карата тигезләп куелырга тиеш, мондый корылманың мәйданы койма секциясе мәйданының 75 процентыннан артмаска тиеш.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының халык яшәешен тәэмин итү һәм шәһәр төзелеше буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме
вазифаларын башкаручы Ф.И. Андреева